| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>**25.04.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 390** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 62 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 26 августындагы 92 номерлы, 2023 елның 30 маендагы 288 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2004 елның 24 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районы Советы Регламенты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 24 мартындагы 62 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 26 августындагы 92 номерлы, 2023 елның 30 маендагы 288 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктының «а» пунктчасында «, Зеленодольск муниципаль районы сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында «,Зеленодольск муниципаль районы сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. бишенче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 2.1 өлеш белән тулыландырырга:

«2.1. Депутат, коррупциягә каршы тору максатында, 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгәне һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затларга «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылса, җаваплылыктан азат ителә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы

составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, район Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**